| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ<br>ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ<br>ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И<br>КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,<br>АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ<br>И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ<br>(Госалкогольинспекция Республики Татарстан) | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ<br>ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ<br>ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ<br>КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН<br>ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ<br>(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе) |

# ПРИКАЗ

26.09.2019 — № 10-07/161

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең норматив актларын юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыруны регламентлаучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Р.Ә.Арслановка йөкләргә.

Җитәкче — Җ.Й.Әхмәтханов

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2019 елның «26» 10 10-07/161 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «тәртип» сүзен «эзлеклелек» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле бишенче һәм алтынчы абзацлар өстәргә:

«3) алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату күләме турында, шәраб продукциясе җитештерү өчен җыелган виноград күләме турында декларацияләр тапшыруга дәүләт контроле.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата төбәк дәүләт контроле әлеге Регламентта каралган тәртиптә, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла».»;

1.2 пунктның икенче абзацында «лицензияләү бүлеге» сүзләреннән соң «алкогольле продукция әйләнешенә контрольлек итү һәм кулланучылар базары торышын анализлау бүлеге, оператив муниципальара контроль бүлеге,» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 171-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе

законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4553 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 1997 елның 15 августындагы 1036 номерлы карары (алга таба – Җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләре)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 34, 3980 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Товарларның аерым төрләрен сату кагыйдәләрен, ремонт яки алмаштыру чорына сатып алучының аналогик товарга алмаштыру турындагы таләбе кагылмый торган озак файдаланудагы товарлар исемлеген һәм кайтарылырга яки башка үлчәм, форма, габарит, фасон, төстәге яки комплектациядәге аналогик товарга алмаштырылырга тиешле булмаган сыйфатлы азык-төлек булмаган товарлар исемлеген раслау турында» 1998 елның 19 гыйнварындагы 55 номерлы карары (алга таба – Товарларның аерым төрләрен сату кагыйдәләре) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 4, 482 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү, әйләнеше һәм (яки) куллану күләме, җитештерү куәтләреннән файдалану турында, җыелган виноград күләме һәм виноградлы шәраб продукциясе җитештерү өчен кулланылган виноград күләме турында декларацияләр тапшыру хакында» 2012 елның 9

августындагы 815 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 815 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 34, 4735 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше күләмен исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы эшчәнлеге турында» 2015 елның 29 декабрендәге 1459 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 2 335, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, басылып чыгу номеры: (0001201702140002));

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство карамагында

торган оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеге (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, № 85, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Алкоголь базарын җайга салу буенча федераль хезмәтнең «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция житештерү, әйләнеше һәм (яки) аннан файдалану күләме, җитештерү куәтләреннән файдалану турында декларацияләр тутыру тәртибе турында» 2012 елның 23 августындагы 231 номерлы боерыгы (Российская газета, 2012, 13 сентябрь, № 210, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Алкоголь базарын җайга салу буенча федераль хезмәтнең «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү, әйләнеше һәм (яки) куллану күләме, җитештерү куәтләреннән файдалану турында электрон документ формасында декларацияләр тапшыру форматы турында» 2013 елның 5 августындагы 198 номерлы боерыгы (алга таба – 198 номерлы Росалкогольрегулирование боерыгы);

Россия Финанс министрлыгының «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнеше күләмен, алкогольле продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешма һәм, алга таба ваклап сату өчен, сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, медовуха сатып алуны гамәлгә ашыручы шәхси эшкуар турында, алкоголь продукциясе, алкоголь продукциясен ваклап сату күләме турында, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатуга рөхсәт бирә һәм озата бара торган документлар турында мәгълүматны исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәү турында электрон рәвештәге гаризаларны тапшыру формаларын һәм срокларын, шулай ук күрсәтелгән мәгълүмат системасында мәгълүматның теркәүгә алынуына раслама һәм мәгълүматны теркәүгә алудан баш тарту турында хәбәр итү формаларын һәм срокларын раслау турында» 2016 елның 15 июнендәге 84н номерлы (алга таба – Россия Финанс министрлыгының 84н номерлы боерыгы)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 30 август, басылып чыгу номеры (0001201608300039);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге

817 номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, басылып чыгу номеры: 0001201703210041);

Россия Финанс министрлыгының «Оешманың, шәхси эшкуарның, авыл хуҗалыгында товар җитештерүченең, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинның этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү күләме турында, җитештерү куәтләреннән файдалану турында, җыелган һәм шәраб продукциясен җитештерү өчен кулланылган виноград күләме турында төзәтмәләр кертә торган декларация тапшыру турындагы гаризасын билгеләнгән сроктан соң тапшыру һәм билгеләнгән сроктан соң төзәтмәләр кертә торган декларацияләрне тапшыру мөмкинлеге турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 20 июнендәге 97н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 17 июль, басылып чыгару номеры (0001201707170021);

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2003, 17 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Республика Татарстан, 2015, 7 март, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 елның 5 августындагы 391 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмә («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, № 30, 2005 ел, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле продукцияне ваклап сатучы оешмаларның түләнгән устав капиталының минималь күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары һәм карарларының нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2014 елның 15 мартындагы 161 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 161 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм

республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 23);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 10 декабрендәге 1104 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1104 номерлы карары) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2018, № 95).»;

1.4 пунктта «җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәткәндә» сүзләреннән соң «, шул исәптән алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату күләмен, шәраб продукциясе җитештерү өчен җыелган виноград күләмен декларацияләү өлешендә» сүзләрен өстәргә;

2 бүлектә:

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Алкогольле продукцияне ваклап сатучы лицензиатларны, шәрабне ваклап сатудан тыш, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган шәрабны (шәмпан шәрабын) ваклап сатучы лицензиатларны планлы тикшерүләр үткәрелми.

Планлы тикшерүләр җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиясе булган лицензиатларга карата уздырыла. Планлы тикшерүләр үткәрү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

2.15 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац белән өстәргә:

«в) товарларны маркировкалау таләпләре бозылу;»;

2.16 пунктта «2 пунктчаның «а» һәм «б» абзацларында» сүзләрен «2 пунктчада» сүзләренә алмаштырырга;

2.23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.23. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге ТР Министрлар Кабинетының 1104 нче карары белән расланган.

Тикшерү уздыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән һәм үзләренә карата тикшерүләр уздырыла торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булып тормаган экспертлар, аккредитацияләүнең илкүләм системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән эксперт оешмалары җәлеп ителергә мөмкин.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары турында» 2011 елның 26 сентябрендәге

198 номерлы боерыгы белән расланган ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге.»;

3 бүлектә:

2 нче таблицаның 1 бүлегендә – Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге:

2 графада:

1.4 пунктта «171-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 3.1 пунктында күрсәтелгән мондый продукция турында мәгълүматлар» сүзләрен «БДАМС идентификаторы булган ике үлчәмле штрих коды» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «171-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 3.1 пунктында күрсәтелгән мондый продукция турында мәгълүматлар» сүзләрен «БДАМС идентификаторы булган ике үлчәмле штрих коды» сүзләренә алмаштырырга;

1.11 пунктның 2 һәм 3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә акциз маркалары белән маркировкаланучы чит илдән кертелгән, әйләнешенең күләме турындагы мәгълүмат алкоголь продукциясенең һәр берәмлеге буенча бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлмәгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен таможня декларациясенә теркәп бирелә торган белешмә. Мондый белешмә ЕАЭС товарлары булган, чит илдән кертелгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен тутырылмый;

3) Россия Федерациясе территориясендә җитештерелгән яисә чит илдән кертелгән һәм ЕАЭС товарлары булган, әйләнешенең күләме турындагы мәгълүмат алкоголь продукциясенең һәр берәмлеге буенча бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлмәгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен, шулай ук 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә махсус маркалар белән маркировкаланучы алкогольле продукция өчен товар-транспорт накладнойларына теркәп бирелә торган белешмә»;

1.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.17. Федераль махсус маркада һәм акциз маркасында күрсәтелгән маркаларны җитештерүче оешма тарафыннан төшерелгән һәм кодлаштырылган рәвештә БДАМС идентификаторын үз эченә алган ике үлчәмле штрих коды (кодлаштырылган рәвештәге график мәгълүмат) булырга тиеш.

БДАМС идентификаторы хәрефләрнең һәм саннарның федераль махсус марканы һәм алкоголь продукциясен маркалаштыра торган акциз маркасын, шулай ук БДАМС системасында теркәлгән башка белешмәләрне билгеләргә мөмкинлек бирә торган уникаль ярашуыннан гыйбарәт»;

1.17 пунктның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«171-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 3.1 пункты»;

2 графада:

1.19 пунктның бишенче абзацында «тимер юл транспортында» сүзләреннән соң «, шулай ук торак фондының торак урыннарында» сүзләрен өстәргә;

1.24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.24. Шәһәр торак пунктларында алкогольле продукцияне (сыра, сыра эчемлекләреннән, сидр, пуаре, медовухадан тыш) ваклап сатучы оешмалар мондый максат өчен милектә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки арендага алынган (срогы килешүдә билгеләнеп, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән), алкогольле продукцияне ваклап сату башкарыла торган аерым бүлекчәнең һәр урнашкан урыны буенча гомуми мәйданы 50 квадрат метрдан ким булмаган стационар сәүдә объектларына һәм склад бүлмәләренә ия булырга тиеш.

Авыл торак пунктларында алкогольле продукцияне (сыра, сыра эчемлекләреннән, сидр, пуаре, медовухадан тыш) ваклап сатучы оешмалар мондый максат өчен милектә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки арендага алынган (срогы килешүдә билгеләнеп, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән), алкогольле продукцияне ваклап сату башкарыла торган аерым бүлекчәнең һәр урнашкан урыны буенча гомуми мәйданы 25 квадрат метрдан ким булмаган стационар сәүдә объектларына һәм склад бүлмәләренә ия булырга тиеш.

Сыра, сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуха ваклап сатучы оешмалар һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуха ваклап сатучы шәхси эшкуарлар мондый максат өчен милектә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки арендага алынган стационар сәүдә объектларына һәм склад бүлмәләренә ия булырга тиеш.

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр дип танылган һәм үзләре тарафыннан җитештерелгән шәраб, күбекле шәраб (шәмпан) ваклап сатучы крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси эшкуарлар мондый максат өчен милектә яки арендага алынган стационар җитештерү биналарына һәм (яки) сәүдә объектларына ия булырга тиеш.

Крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр дип танылган шәхси эшкуарлар тарафыннан җитештерелгән шәрабны, күбекле шәрабны (шәмпан шәрабын) ваклап сату әлеге продукцияне җитештерү урнашкан урын буенча эш стационар җитештерү биналарында һәм (яки) сәүдә объектларында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 10 пунктының беренче-өченче абзацларында күрсәтелгән аерым бүлекчәнең урнашу урыны буенча аерым склад урыннары булу турындагы таләпләр пошлинасыз сәүдә итүче кибетләрдә алкогольле продукцияне ваклап сатуга кагылмый.

171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 10 пунктының беренче-өченче абзацларында күрсәтелгән стационар сәүдә объектларына һәм

склад бүлмәләренә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

Шәһәр һәм (яки) авыл торак пунктларында алкогольле продукцияне (әзер продукциядәге этил спиртының күләме 16,5 проценттан артмаган алкогольле продукциядән тыш) ваклап сатучы оешмалар (бюджет учреждениеләреннән тыш), җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәткәндә, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәр урыны буенча мондый максатлар өчен милектә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки арендага алынган (срогы килешүдә билгеләнеп, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән) стационар җәмәгатьне тукландыру объектларына ия булырга тиеш.

Шәһәр һәм (яки) авыл торак пунктларында күләмендә этил спирты әзер продукциянең 16,5 процентыннан артмаган алкогольле продукцияне ваклап сатучы оешмалар (бюджет учреждениеләреннән тыш) һәм сыра, сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуха ваклап сатучы шәхси эшкуарлар, җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәткәндә, мондый максатлар өчен милектә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки арендага алынган, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәр урыны буенча җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәтүдә файдалану өчен планлаштырыла торган җәмәгатьне тукландыру объектына ия булырга тиеш.

Шәһәр һәм (яки) авыл торак пунктларында алкогольле продукцияне (әзер продукциядәге этил спиртының күләме 16,5 проценттан артмаган алкогольле продукциядән тыш) ваклап сатучы бюджет учреждениеләре, җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәткәндә, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәр урыны буенча мондый максатлар өчен оператив идарәгә тапшырылган, түләүсез кулланылышта булган яки арендага алынган (срогы килешүдә билгеләнеп, бер һәм аннан күбрәк ел тәшкил иткән) стационар җәмәгатьне тукландыру объектларына ия булырга тиеш.

Шәһәр һәм (яки) авыл торак пунктларында әзер продукциядәге этил спиртының күләме 16,5 проценттан артмаган алкогольле продукцияне ваклап сатучы бюджет учреждениеләре, җәмәгатьне тукландыру хезмәтләрен күрсәткәндә, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәр урыны буенча мондый максатлар оператив идарәгә тапшырылган, түләүсез кулланылышта булган яки арендага алынган җәмәгатьне тукландыру объектына ия булырга тиеш.

Алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сату контроль-касса техникасын кулланып, контроль-касса техникасын куллану турында Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.»;

1.25 пунктның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.26-1.32 пунктлар өстәргә:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1.26. Составында тонусны күтәрә торган матдәләр (компонентлар) булган әзер продукция күләменең 15 проценттан кимрәге этил спирты булган алкогольле продукция әйләнеше рөхсәт ителми. Тонусны күтәрә торган матдәләр (компонентлар) исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 8 пункты | |
| | 1.27. Этил спирты (этанол), алкогольле һәм спиртлы азык-төлек продукциясе, шулай ук әзер продукция күләменең 25 процենттан артыграгы этил спирты булган спиртлы азык-төлек булмаган продукция әйләнеше белән шөгыльләнүче оешмалар түбәндәгеләрнең күләмен декларацияләргә тиеш:<br>- сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуха, спиртлы азык-төлек булмаган продукцияне ваклап сатуны;<br>- җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны;<br>- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә керү мөмкинлеге, шул исәптән «Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән керү ноктасы булмаган торак пунктларында гамәлгә ашырыла торган алкогольле продукцияне ваклап сатуны.<br>Сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы ваклап сатучы шәхси эшкуарлар аларны ваклап сату күләмен исәпкә алырга һәм декларацияләргә тиеш | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 пункты | |
| | 1.28. Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше күләмен исәпкә алу тәртибе, этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше күләме турында декларацияләр тапшыру тәртибе һәм әлеге декларацияләрнең формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. | 171-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 пункты | |
| | 1.29. Декларацияләр хисап кварталыннан соң килүче айның 20нче көненнән соңга калмыйча, квартал саен тапшырыла. | РФ Хөкүмәтенең 815 номерлы карары белән расланган Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү, әйләнеше һәм (яки) куллану күләме, җитештерү куәтләреннән | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | файдалану турында, җыелган виноград күләме һәм виноградлы шәраб продукциясе җитештерү өчен кулланылган виноград күләме турында декларацияләр тапшыру кагыйдәләренең 15 пункты (алга таба – Декларацияләр тапшыру кагыйдәләре) | |
| | 1.30. Декларацияләр элемтәнең телекоммуникация каналлары аша оешма җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның), шәхси эшкуарның, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенең, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинның «Электрон имза турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә тикшерү ачкычы сертификаты бирелгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында тапшырыла. | Декларацияләр тапшыру кагыйдәләренең 16 пункты | |
| | 1.31. Декларацияләр оешманың (шәхси эшкуарның) теркәлү урыны буенча Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына тапшырыла.<br>Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына тапшырыла торган декларацияләрнең күчермәләрен оешмалар һәм шәхси эшкуарлар, декларацияләр Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарына тапшырылганнан соң бер тәүлек эчендә, электрон рәвештә Алкоголь базарын җайга салу буенча федераль хезмәткә җибәрәләр.<br>Электрон документ рәвешендә декларацияләр тапшырганда, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формат кулланыла. | Декларацияләр тапшыру кагыйдәләренең 18 пункты | |
| | 1.32. Агымдагы хисап чорында оешма, шәхси эшкуар, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданин кирәкле белешмәләрнең чагылдырылмавы яки аларны чагылдыруның тулы булмау фактларын ачыклаган очракта, шулай ук элек тапшырылган декларациядә | Декларацияләр тапшыру кагыйдәләренең 20 пункты | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хаталар (ялгышлар) җибәрелгән булуы ачыкланганда, әлеге затлар элегрәк тапшырылган декларацияләрдә булган мәгълүматларны тәгаенләштерә торган белешмәләрне (өстәмәләрне) үз эченә алган төзәтмә кертә торган булган декларацияләрне тапшыра.<br>Төзәтмәләр кертә торган декларацияләр хисап кварталыннан соң килүче квартал өчен декларацияләр тапшыру вакыты чыкканчыга кадәр, тапшырылган белешмәләрнең тулылыгы яки дөрес булмавы аркасында килеп чыккан сәбәпләрне нигезләп тапшырыла (Декларацияләр тапшыру кагыйдәләренең 21 пунктында каралган очраклардан тыш). | | |

»;

4 бүлектә:

3 нче таблицада:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге»;

9 нчы һәм 10 нчы юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелгән яисә чит илдән кертелгән һәм ЕАЭС товарлары булган, әйләнешенең күләме турындагы мәгълүмат алкоголь продукциясенең һәр берәмлеге буенча этил сиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнеше күләмен исәпкә алуның БДАМС системасында теркәлмәгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә махсус маркалар белән маркировкаланучы алкогольле продукция өчен товар-транспорт накладнойларына теркәп бирелә торган белешмә | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Этил спиртына (этил спиртының фармацевтика субстанциясеннән (этанолдан) тыш), алкогольле һәм спиртлы продукциягә (спиртлы дару препаратларыннан һәм спиртлы медицина эшләнмәләреннән тыш) товар-транспорт накладноена белешмә хакында» 2005 елның 31 декабрендәге 864 номерлы карары («Этил спиртына (этил спиртының фармацевтика субстанциясеннән (этанолдан) тыш), алкогольле һәм спиртлы продукциягә (спиртлы дару препаратларыннан һәм спиртлы медицина эшләнмәләреннән тыш) товар-транспорт накладноена белешмә тутыру кагыйдәләре» белән бергә) |
| 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә акциз маркалары белән маркировкаланучы чит илдән кертелгән, әйләнешенең күләме турындагы мәгълүмат алкоголь | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Таможня декларациясенә теркәлә торган белешмә турында» 2005 елның 31 декабрендәге 872 номерлы карары |

| | |
|---|---|
| продукциясенең һәр берәмлеге буенча бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлмәгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен таможня декларациясенә теркәп бирелә торган белешмә. Мондый белешмә ЕАЭС товарлары булган, чит илдән кертелгән алкогольле һәм спиртлы продукция өчен тутырылмый | (Таможня декларациясенә теркәлә торган белешмә тутыру кагыйдәләре белән бергә) |

«;

5 бүлектә:

5.2 пунктның дүртенче абзацында «2.12, 2.13 пунктларында» сүзләрен «2.13 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Еллык планга үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

а) тикшерү Еллык планнан төшереп калдырылганда:

бетерелүенә бәйле рәвештә юридик зат эшчәнлегенә планлы тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмау сәбәпле, физик зат тарафыннан шәхси эшкуар буларак эшчәнлеге туктатылу сәбәпле, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмау сәбәпле;

294-ФЗ номерлы Федераль законның $26^1$ статьясында каралган очракларда, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан тиешле тикшерүне еллык планнан төшереп калдыру турында карар кабул ителгәндә;

294-ФЗ номерлы Федераль законның $26^2$ статьясында каралган очракларда, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан тиешле тикшерүне еллык планнан төшереп калдыру турында карар кабул ителгәндә;

лицензиатларга карата планлаштырылган тикшерүләр өчен лицензиянең гамәлдә булуын туктату яки юкка чыгару сәбәпле;

җиңеп булмый торган шартлар башлануына бәйле рәвештә;

б) юридик зат яисә шәхси эшкуар турында Еллык планда күрсәтелгән белешмәләр үзгәргәндә:

юридик зат яисә шәхси эшкуар урнашкан урын яки юридик зат яисә шәхси эшкуар эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны яки адресы үзгәрүгә бәйле рәвештә;

юридик затны үзгәртеп коруга бәйле рәвештә;

юридик затның исеме үзгәрүгә, шулай ук шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә.

Еллык планга үзгәрешләр кертү ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе боерыгы белән гамәлгә ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр билгеләнгән тәртиптә алар кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) тиешле кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ

формасында тиешле прокуратура органына җибәрелә, шулай ук үзгәрешләр кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5.75 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.75. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазыйфаи затлары тарафыннан түбәндәге формада гамәлгә ашырыла:

«Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында алкогольле һәм спиртлы продукция турында мәгълүмат урнаштырганда зарури таләпләрнең һәм тыюларның үтәлешен күзәтү;

юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе актлары нигезендә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшырырга тиешле булган (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә) яки ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе актларында каралмаган йөкләмәләрне йөкләмичә алынырга мөмкин булган мәгълүматларга анализ ясау юлы белән зарури таләпләрнең, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

ваклап сатканда алкогольле продукциягә минималь бәя күләмнәренә, алкогольле продукцияне ваклап сату вакытын, шартларын һәм урыннарын чикләүгә, җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга карата зарури таләпләрнең, спиртлы продукцияне ваклап сатуга карата таләпләрнең үтәлешен сәүдә объектларын һәм җәмәгатьне тукландыру предприятиеләрен мониторинглау юлы белән күзәтү»;

5.77 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.77. Йөкләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) йөкләмәнең номеры һәм датасы;

б) Йөкләмә ала торган вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

в) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чарасының төре:

«Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында алкогольле һәм спиртлы продукция турында мәгълүмат урнаштырганда зарури таләпләрнең һәм тыюларның үтәлешен күзәтү;

юридик затның яки шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында законнар нигезендә әлеге затларга аны тапшыру җаваплылыгы йөкләнгән мәгълүматларны анализлау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен

күзәтү (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән);

ваклап сатканда алкогольле продукциягә минималь бәя күләмнәренә, алкогольле продукцияне ваклап сату вакытын, шартларын һәм урыннарын чикләүгә, җәмәгатьне тукландыру хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга карата зарури таләпләрнең, спиртлы продукцияне ваклап сатуга карата таләпләрнең үтәлешен сәүдә объектларын һәм җәмәгатьне тукландыру предприятиеләрен мониторинглау юлы белән күзәтү;

г) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек итү объектлары һәм (яки) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек итү объектлары урнашкан территорияләр турында белешмәләр;

д) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасын уздыру вакытының чоры, яки билгеле бер чорга бәйләнешкә кермичә дәүләт контроле буенча чара уздыруның исәпле холкына күрсәтү (бер тапкыр, күп тапкыр);

е) Йөкләмәне төзегән затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары;

ж) Йөкләмәне раслаган вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары һәм имзасы.»;

5.78 пунктта «хисап» сүзен «бәяләмә» сүзенә алмаштырырга;

7 бүлектә:

7.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Әгәр язмача рәвештәге шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе (юридик затның аталышы), яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон почта адресы) күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек

бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе, Дәүләт алкоголь инспекциясе вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле зат, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаять белән мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән мондый язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлегенең булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.»

Контроль-инспекция бүлеге
башлыгы___________________/Т. М. Хәбибуллина/______________

Административ һәм
суд практикасы бүлеге
башлыгы________________________/Б. Г. Эйдинов/________________

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе
урынбасары____________________/Р.Ә.Арсланов/____________